**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменений в состав Совета при Президенте Республики Татарстан по межнациональным и межконфессиональным отношениям

В связи с переходом отдельных лиц на другую работу **постановляю**:

1. Внести в состав Совета при Президенте Республики Татарстан по межнациональным и межконфессиональным отношениям (далее – Совет), утвержденный Указом Президента Республики Татарстан от 30 января 2013 года № УП-71 «Об образовании Совета при Президенте Республики Татарстан по межнациональным и межконфессиональным отношениям» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 9 октября 2013 года № УП-1007 и от 1 ноября 2014 года № УП-1015), следующие изменения:

а) вывести из состава Совета Д.У. Иманалиева, А.М. Меткина, И.З. Миннахметова, М.Х. Салихова, Г.И. Сергееву, И.К. Хайруллина, С.В. Чепуштанова, К.Г. Яковлева;

б) ввести в состав Совета:

Алеге Алию Агбоола – президента Ассоциации иностранных студентов и аспирантов города Казани (по согласованию);

Демидова Виктора Николаевича – начальника Управления Министерства юстиции Российской Федерации по Республике Татарстан (по согласованию);

Забегину Татьяну Вениаминовну – члена Общественной палаты Российской Федерации, заместителя председателя Общественной палаты Республики Татарстан (по согласованию);

Зарипова Айрата Ринатовича – руководителя Республиканского агентства по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа»;

Кузнецова Артема Александровича – начальника Управления Федеральной миграционной службы по Республике Татарстан (по согласованию);

Феофана (Ашуркова Ивана Андреевича) – митрополита Казанского и Татарстанского (по согласованию);

в) изложить в следующей редакции наименования должностей членов Совета:

С.К. Джаксыбаева – «руководитель Национально-культурной автономии казахов Республики Татарстан (по согласованию)»;

Н.Г. Магдеева – «глава муниципального образования «город Набережные Челны» (по согласованию)».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань,Кремль
14 ноября 2015 года
№ УП-1098

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча совет составына үзгәрешләр кертү турында

Аерым затларның башка эшкә күчүләре сәбәпле **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча совет төзү турында» 2013 елның 30 гыйнварындагы ПУ-71 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 9 октябрендәге ПУ-1007 номерлы һәм 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1015 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча совет (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан Д.Ү. Иманалиевны, А.М. Меткинны, И.Җ. Миңнәхмәтовны, М.Х. Салиховны, Г.И. Сергееваны, И.К. Хәйруллинны, С.В. Чепуштановны, К.Г. Яковлевны чыгарырга;

б) Совет составына кертергә:

Алеге Алию Агбооланы – Казан шәһәренең Чит илләр студентлары һәм аспирантлары ассоциациясе президентын (килешү буенча);

Демидов Виктор Николаевичны – Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Забегина Татьяна Вениаминовнаны – Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасарын (килешү буенча);

Зарипов Айрат Ринат улын – Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесен;

Кузнецов Артем Александровичны – Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Феофанны (Ашурков Иван Андреевичны) – Казан һәм Татарстан митрополитын (килешү буенча);

в) Совет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Җаксыбаев Сәгыйть Кодыбай улының – «Татарстан Республикасы Казах милли-мәдәни мохтарияте җитәкчесе (килешү буенча)»;

Н.Г. Мәһдиевнең – «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 14 ноябрь
№ ПУ-1098